РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

САБИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН

СОВЕТ САТЫШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

422070, Республика Татарстан, Сабинский район,
С.Сатышево, ул. Советская, 24
тел. (8262) 48-3-31

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ

САТЫШ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422070, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Сатыш авылы, Совет урамы, 24 йорт
тел. (8262) 48-3-31

e-mail: Sat.sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ
20.05.2020

КАРАР
№11

# РЕШЕНИЕ

Авыл җирлеге мөлкәте белән эш итү вәкаләтләрен муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында авыл җирлекләре мөлкәте объектлары реестрларын, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына бирү өчен билгеләнгән мөлкәт исемлекләрен бастырып чыгару турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, Саба муниципаль районы Советы мөрәҗәгате һәм «sale.zakazrf.ru электрон сәүдә мәйданчыгыннан файдаланып арендага бирелгән муниципаль мөлкәт өлеше" индикаторын үтәү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 21.01.2020 елдагы киңәшмәсе Беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Сатыш авыл җирлеге Советы

Карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының Саба муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Сатыш авыл җирлеге башкарма комитеты вәкаләтләрен тапшыру турындагы тәкъдимен кабул итү турында:

- авыл җирлеге милке белән эш итү буенча;

- муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында авыл җирлекләре мөлкәте объектлары реестрларын, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына бирү өчен билгеләнгән мөлкәт исемлекләрен бастырып чыгару буенча.

2. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Сатыш авыл җирлеге башкарма комитетына:

- Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзергә;

- әлеге карарны тормышка ашыру максатында, бюджет закончалыкларына туры китереп, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Сатыш авыл җирлеге Советына «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Сатыш авыл җирлеге Советының 2020 елга һәм 2021 – 2022 еллар план чорына бюджеты турында " 2019 елның 19 декабрендәге 32 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында" гы Карары проектын эшләргә һәм карау өчен тәкъдим итергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Сатыш авыл җирлеге башлыгы Ф.Ф.Шафигуллин